**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«25» 02. 2020 ел Яр Чаллы ш. № 401

Муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр уздыруның административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатында, 2015 елның 3 ноябрендәге 306-ФЗ номерлы «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе хакында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары, Башкарма комитетның «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2018 елның 6 августындагы 3794 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тукай муниципаль районы территориясендә җирләрдән файдалануга муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын расларга.
2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең «Тукай муниципаль районы территориясендә җирләрдән файдалануга муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 29 июнендәге 1860 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Районның мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына өч эш көне дәвамында Тукай муниципаль районы территориясендә җирләрдән файдалануга муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрү буенча муниципаль хезмәт

күрсәтүнең административ регламентын районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Г. Авзалов